РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 30.09.2025 1579 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында исәпләүләр тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнар гаиләләренә ярдәм итү буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган, яки контракт буенча хәрби хезмәт узучы, ирекле ярдәм турында контракт төзегән гражданнарының гаиләләренә өстәмә ярдәм чаралары хакында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 6 июнендәге 802 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 5 мартындагы 461 номерлы карары, Россия Федерациясе оборона министрының «Россия Федерациясе Оборона министрлыгында Россия Федерациясе гражданнарының Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожск өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу фактын һәм Россия Федерациясе Оборона министрлыгы тарафыннан ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасын кулланып махсус хәрби операциядә катнашу турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында» 2024 елның 11 октябрендәге 612 номерлы боерыгы нигезендә, Алабуга муниципаль район Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районының муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында исәпләүләр тәртибен раслау турында» 2020 елның 10 июнендәге 471 номерлы карары белән расланган, Алабуга муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы караган һәм тәрбияләгән өчен ата-ана

түләвен формалаштыру һәм алу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карар тәртибенең 1.4. пунктындагы 13 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-хәрби хезмәт вакытында яисә хәрби хезмәттән азат ителгәннән яисә контракт туктатылганнан соң гарипләнү (яралану, җәрәхәтләнү, контузия) аркасында инвалидлык билгеләнгән яисә авыру алынган булса, хәрби хезмәткәрләрнең балаларының ата-аналары (законлы вәкилләре); ветераннар, хәрби хәрәкәт инвалидлары, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак булганнар-махсус хәрби операциядә сугышчан бурычларны үтәү барышында имгәнүләрне раслый торган документ, махсус хәрби операциядә катнашучының һәлак булуы турында хәбәр итү;».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ
СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП
Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1579 от 30.09.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 25.09.2025 12:58

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 25.09.2025 - 18:45 | - |